## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**“05 ” апрель 2024 ел № 3**

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлегенең Кәче авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 24 ноябрендәге 3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлегенең Кәче авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 25 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге Кәче авылында 2024 елның 05 апрелендә «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлегенең Кәче авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 24 ноябрендәге 3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсен яңа редакциядә бәян итү өлешендә халык җыены беркетмәсе тәзелде:

«Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге Кәче авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 75 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- торак пункт чиктәрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, төзекләндерү, карап тоту (Кәче авылының Тау асты урамы 207 нче йорттан, Болынлык урамына кадәр юл-урам челтәрендәге автомобиль юлларын вак таш белән тигезләү.

- Кәче авылы урам челтәренең юл полотносы чокырларын ямау, Үзәк урам 121 а нче йорттан 203 нче йортка кадәр; Бакча урамы).

Аерым мәсьәләләр буенча экономия булганда, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны җыенда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга.

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»»

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучы сайлау хокукына ия затлар исемлегенә 657 граждан, тавыш бирүдә катнашкан 336 граждан кертелде.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашучы 318 кеше тавыш бирде; “Каршы" позициясе өчен җыенда катнашучы 18 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге Кәче авылында халык җыены узды, җыен нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2. «Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге Кәче авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 75 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- торак пункт чөлтәрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, төзекләндерү, карап тоту (Кәче авылының Тау асты урамы 207 нче йорттан, Болынлык урамына кадәр юл-урам челтәрендәге автомобиль юлларын вак таш белән тигезләү.

- Кәче авылы урам челтәренең юл полотносы чокырларын ямау, Үзәк урам 121 а нче йорттан 203 нче йортка кадәр; Бакча урамы).

Аерым мәсьәләләр буенча экономия булганда, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны җыенда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга» соравы буенча карар кабул ителде дип танырга».

3. Әлеге карарны гражданнар күпләп җыела торган урыннарда: ТР, Арча районы, Кәче авылы, Үзәк урам, 200 йорт адресы буенча мәгълүмат стендында, Арча муниципаль районның (http://arsk.tatarstan.ru) рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Арча муниципаль районы
Кәче авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Гәрәев